Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № Х-4**

Котлы Бөкәш авылы 12 октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 статьясындагы 3 пунктының 3 пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 09.02.1995 ел, № 74 карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында өстәмә нигезләмәне расларга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов